СТАРОАЙМАНОВСКИЙ
СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
село Старое Айманово, ул.Новая,
дом5А 423739

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Иске Айман авылы, Яна ур, 5А
йорт 423739

Тел/факс (885552)5-01-63
Saym.Akt@yandex.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

01.апреля 2020ел №7

**« Иске Айман авыл җирлеге территориясендә гражданнарның беренчел хәрби исәбен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл башкарма комитетының 18.06.2019 ел № 14 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 1996 елның 31 маендагы "Оборона турында", 1998 елның 28 мартындагы "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында», 1997 елның 26 февралендәге "Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизацияләү турында", Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы "Хәрби исәпкә алу турында Нигезләмә" һәм 26.02.98 ел., 258 номерлы "Россия Федерациясе Кораллы Көчләре запасында торучы Россия Федерациясе гражданнарын, федераль башкарма хакимият органнарын, запасы булган һәм дәүләт хакимияте органнарында, авыл җирлеге органнарында һәм оешмаларда эшләүче Россия Федерациясе гражданнарын броньлау буенча төп нигезләмәләр", федераль законнарны үтәү йөзеннән, Актаныш муниципаль районы Иске Айман башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. « Иске Айман авыл җирлеге территориясендә гражданнарның беренчел хәрби исәбен оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Айман авылы башкарма комитетының 2019 елның 18 июнь №14 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең III бүлегенең 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- 3.2. Җирле үзидарә органы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган территориядә яшәүче яки торучы (3 айдан артык вакытка), шул исәптән яшәү урыны һәм (яки) тору урыны буенча теркәлмәгән гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында « Иске Айман авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Айман авылы
башкарма комитеты җитәкчесе М.Р.Ахметханов

Староаймановский сельский исполнительный комитет
ИНН 1604007...
ОГРН 1061682011258